**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1729**
**07.04.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибе турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгыннар чыгуга юл куймау максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 7 апрелендәге
1729 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә янгынга каршы махсус режим билгеләү
тәртибе

1. Янгын куркынычы арткан очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә Башкарма комитет карары белән янгынга каршы махсус режим билгеләнә.

2. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә балаларның җәйге ял урыннарында, коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендә түбәндәге өстәмә янгын куркынычсызлыгы таләпләре билгеләнә:

1) тиешле территорияләрдә янгын куркынычсызлыгы торышына һәм таләпләренең үтәлешенә коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре рәисләре, шулай ук балаларның җәйге ялын оештыручы оешмалар җитәкчеләре тарафыннан тәэмин ителә торган даими контрольне гамәлгә ашыру;

2) аерым участокларда учак ягуларны, янгын чыгу куркынычы булган эшләр башкаруны вакытлыча туктату.

3. Балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыручы (шул исәптән балалар көндез була торган) оешмалар җитәкчеләренә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) ел саен, җәйге ял лагере эшли башлаганчы, балалар ялын үткәрү чорына янгыннар чыгуга юл куймау буенча чаралар планын эшләргә һәм аны ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш идарәсенең Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре бүлеге белән килештерергә;

2) һәр смена башланыр алдыннан хезмәткәрләр белән янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын була калса эш итүләр буенча инструктажлар үткәрергә;

3) янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын була калса эш итүләр буенча инструктажларны ял лагерына килүче һәр бала белән үткәрергә;

4) сменага кимендә бер тапкыр, янгын була калса эвакуацияләү планнарын үтәү буенча практик тренировкалар үткәрергә.

4. Яр Чаллы шәһәре территориясендә коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре рәисләренә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрендәге җир участокларын һәм алар янәшәсендәге территорияләрне яна торган калдыклардан, чүпләрдән, тарадан һәм корыган үсемлекләрдән чистартуны тәэмин итәргә;

2) коммерцияле булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзалары арасында бакчачылык җәмгыяте территориясен көн саен карап чыгу мәсьәләсе буенча эшне оештырырга;

3) янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда чүпләрне, яна торган калдыкларны, тара һәм корыган үсемлекләрне яндыруга юл куймаска.

5. Янгынга каршы махсус режим билгеләнгәндә, гражданнарның «Яр буе» паркы урман-парк зонасына керүләрен, шулай ук анда транспорт чаралары керүне чикләү гамәлдә була.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова